ЯШЕЛ БИШЕК

ТР ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ РЕСУРСЛАР МИНИСТРЛЫГЫ БЕЛӘН ӘЗЕРЛӘНГӘН МАХСУС КУШЫМТА

# Күңелем Зөя буенда

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ



**Татарның күп җырлары табигать, туган як һәм мәхәббәт турында. Шуны истә тотканда, халкыбыз бакый заманнардан экология хакында гына кайгыртып, аны гына мәрхәбәләп яшәгән дип уйларсың. Моннан биш ай элек экология һәм табигый ресурслар министры итеп билгеләнгән Әгъләм Кыям улы Садретдинов белән очрашкач, сүзне шуннан башламыйча булмады.**

**– Әгъләм Кыямович, экология сүзе беренче тапкыр кайчан колагыгызга чалынды?**

– Без мәктәптә укыганда бу сүзне кулланмыйлар иде әле. Мин туып-үскән Чичкән авылы табигатьнең бик матур урынына утырган. Гомумән, Чуаш Иле урманнарга, суларга бай. Шуңамы, мин үземне табигать баласы дип саныйм. Моннан 30-40 ел элек, хәзерге кебек әйләнә-тирә мохит бозылыр да аны яклау, саклау өчен махсус белгечләр кирәк булыр, зур-зур акчалар салыныр, дип беребез дә уйламаганбыз.

Ә менә Казан авыл хуҗалыгы институтында, безгә аерым фән буларак кермәсә дә, экологиянең табигатьне саклау белән турыдан-туры бәйле булуын әйбәт төшендерделәр. Ул чакта ук безгә җир фәнен укыттылар, туфрак эрозиясе, гумус турында да, ягулыкны зарарлы матдәләрдән арындыру турында да сөйләделәр. Чынбарлыкта мин ул мәсьәләләр белән Апас районы хуҗалыкларында баш инженер һәм хуҗалык җитәкчесе булып эшләгәндә очраштым.

**– Минемчә, Сезгә ул заманнарда табигать турында артык кайгырмыйча яшәүнең нәтиҗәләрен Буа хакимиятен җитәкләгәндә күзәтергә туры килгәндер.**

– Нигә күзәтергә генә? Мин анда эшкә билгеләнгәндә Буа республикада чистарту корылмалары булмаган дүрт шәһәрнең берсе иде. Мин министрлыкка киткәндә, ул эшләп калды. Без Буа каласын җирне агулап яткан йөзләрчә нәҗес базыннан коткардык.

**– Сез эшләгән чорда Буа шикәр заводы үзе кулланган суны чистартып, кабат куллануга кертерлек итеп көйләргә мәҗбүр булды. Яңгыр суларын агызырлык каналлар төзү өчен проект эшләре башланганын да беләм. Шуңа да карамастан, Буа тирәсендәге авыллар грунт суларының базларга күтәрелүеннән җәфаланалар. Әллә соң кеше табигатькә төзәтеп булмаслык зыян саламы?**

– Чынлап та ул тирәдәге күлләрдән Зөя елгасы белән кушыла торган җир асты юллары томаланган дип раслыйлар белгечләр.

**– Бер районда башкарган эшләрне министрлык колачы белән чагыштырып булмый. Түбән Кама зонасында корылучы заводларның экологиягә мөнәсәбәтен ничек күзәтеп бетермәк кирәк...**

– Күптән түгел без Президент белән бергәләп шул төбәктә булдык. "Нефтехим"ның соңгы елларда төзелгән заводлары, нефть эшкәртү заводы – барысы да экологиягә зыян салмый торган технологиягә көйләнгән. Алабуга, Чаллыга тарала торган газ калдыклары – элеккерәк корылганнарныкы. Хәзер аларның да күбесе яңартыла. "Шин" акционерлык җәмгыятен экологик нормаларга кертү өчен "Татнефть" күп чыгымнар сала. "Нефтехим"ны җылылык белән тәэмин итүче ТЭЦ та үзгәртеп корылды. Әгәр химия гигантлары һәм аның ярдәмче предприятиеләре сафка басканда ук шундый зарарсыз технологияләр уйлап чыгарылган булса, аның тирә-юне моңа кадәр күргән зыянны күрмәс иде.

Моннан тыш, сәнәгать зонасы белән шәһәрне аерып торучы яшел санитар полоса да ныгытыла. Монда өстәмә рәвештә берничә дистә гектар агач утыртылды, һәм ул тагын да дәвам итә. Сүз уңаеннан әйтим, "Оргсинтез" һәм аның тирәсендәге предприятиеләр белән шәһәр арасында шундый яшел пута булдырасы бар.

**– Әлеге сөйләгәннәрне предприятиеләрнең табигать-ана алдындагы бурычларын үтәү дип кабул итәм мин үзем. Экология министрлыгы моңа ничек үз өлешен кертә?**

– Быел бик кыйммәт бәягә Түбән Кама төбәге өчен һавага чыгучы газларның күләмен һәм составын ачыклаучы күчмә лаборатория сатып алдык. Андый катлаулы җайланма әлегә кадәр "Таттрансгаз" җәмгыятендә генә бар иде. Хәзер Түбән Каманың үзен генә түгел, Алабуга, Чаллы шәһәрләрен дә тикшереп торачакбыз. Бу – элегрәк андый эш алып барылмады дигән сүз түгел. Иске стационар лаборатория тикшереп, эшләп торды. Тик хәзер таләп арта бара. Әлмәт, Алабуга, Бөгелмәгә дә алдагы ел башыннан һәрберсе бишәр миллион сумлык лабораторияләр кайтартылачак.

Күргәнегезчә, республикада экологиягә мөнәсәбәт тамырдан үзгәрде. Нинди генә яңа предприятие ачылса да, Минтимер Шәрипович Шәймиевнең беренче соравы шул хакта була. Чит илдән килүче белгечләр Россиянең бер генә төбәгендә дә табигатьне саклауга шушындый кискен таләпләр куелмавын билгеләп үтәләр.

**– Сезнең сөйләвегезчә, предприятиеләр һавага зарарлы матдәләр чыгаруын киметү өстендә эшлиләр. Ә шул ук вакытта Экология министрлыгы яңа лаборатор җиһазлар кайтартып, тикшерү эшләрен көчәйтергә мәҗбүр. Ничектер, күңелдә бер шик уяна. Шушы ике көч арасында өченчесе бар кебек...**

– Өстенә бастыгыз. Ул – транспорт. Соңгы ике елда гына да аның саны өч тапкырга диярлек артты. Безнең белгечләр алардан бөркелгән зарарлы газ күләме предприятиеләрдән чыкканга караганда да күбрәк дип раслыйлар. Моңа тикшерү һәм штраф белән генә каршы торып бетәрлек түгел. Шуңа күрә Хөкүмәт игътибарны моның сәбәбен бетерүгә юнәлтә. "КамАЗ"ның экологик иминлекне тәэмин итәрлек "Евро-3" һәм "Евро-4" двигательләренә көйләнүен беләсез инде. Казанда төтен бөркеп ыргылучы "ПАЗ"ларны да шундый ук двигательгә көйләнгән "НефАЗ"лар һәм чит ил автобуслары алмаштыра. Тик бу – экологиягә бәйле оешмаларның мәшәкате кими дигән сүз түгел. Искелек үзенең урынын бик авырлык белән бушата. Юк-юкта кайбер предприятиеләр, тикшерүчеләр йокымсыраганда, зарарлы калдыкларын йә һавага, йә суга ыргытырга тырышалар.

**– Йоклаганда, дигән сүз туры мәгънәсендәме?**

– Туры һәм кыек мәгънәдә.

(Ахыры 4 нче биттә.)

АБАУ!

## Рәнҗеш

Мин өйдә песи тотмыйм. Тик аларны өйләреннән куып чыгаручы хуҗаларына ачуым килә. Машина йөртүчеләр дә песиләрне кызганып тормыйлар. Әле күз генә шундый бер кызганыч вакыйгага юлыктым.

Голубятников урамындагы тукталышта автобус көтәм. Урам аша бик матур гына песи чыгып килә. Үзе чиста, үзе таза. "Бу берәр әйбәт гаиләдә тәрбияләнә торгандыр", – дип уйларга гына өлгергән идем, ниндидер җиңел машина моны кагып китте. Ул да булмады, икенче бер чит ил машинасы өстеннән үк узды. Руль артында утыручы тәрәзәдән башын чыгарып елмайгандай итте. Шул чакны тукталышта тора торган бер бала кычкырып-кычкырып еларга тотынды. Дәү әнисе аны туктатмакчы була:

– Үз башыңа булгыры! Мәче генә түгел, кеше баласын таптатып үтәр. Күзләрен тондырып чабалар, – дип ул машина йөртүчене дә тиргәп алды. Бераздан автобус килеп, без шул ике машина киткән якка таба юл алдык. Берничә тукталыштан соң автобусыбызның урынсыз тукталуына аптырап тәрәзәгә күз салсак, аптырап киттек, урам уртасына халык җыелган. Мәчене таптатып үткән чит ил машинасы "КамАЗ" белән бәрелешкән икән.

Икенче, шундыйрак вакыйганы Тельман урамында күзәттем. Ташландык өй янында бер песи утыра. Каяндыр җиде-сигез эт килеп чыкты да дәррәү мәчегә ташланды. Тегесе стена буенда утырганга күрә качарга өлгермәде. Менә-менә этләр аны әләктереп ала дигәндә ярдәмгә ташландым. Үзем таяк белән селтәнәм, үзем куркам. Тик өлгермәдем, этләр песигә зыян салып өлгергән иде.

Уйлап торам әле менә. Кайчакта этләр белән кешеләр арасында да әллә нинди зур аерма булмый.

**Рафаэль САЛЬМУШЕВ.**
**Казан**

# Каргалар һәм артышлар

ЛАУРЕАТЛАР

**Республикада нибары ике районда – Кукмарада һәм Балтачта үтүче яшь экологларның чираттагы конференциясе шушы кадәр кызыклы булыр дип һич тә уйламаган идем. Баксаң, укытучы абый-апалары белән бергә район балалары табигатьне саклау-өйрәнү юнәлешендә әллә ниләр майтара икән.**



Әлеге конференциянең Салавыч мәктәбендә үтүе дә тикмәгә түгел. Соңгы елларда бер-бер артлы К.Насыйри бүләгенә, "Ел мәктәбе", сәламәтлек буенча Алтын дәрәҗәдәге мәктәп исемнәренә, 2007 елда Путин грантына лаек булган бу коллектив яшь буынга экологик тәрбия һәм белем бирү юнәлешендә дә гаҗәп эшләр майтара.

Бу көнне мәктәп яны бакчасында зәңгәр чыршылардан торган "Мәктәпләр дуслыгы" аллеясы барлыкка килде. Бер тәүлек дигәндә уй-хыялдан чынбарлыкка әйләнгән ясалма чишмәне ачу тантанасы үтте. Әлеге чишмә мәктәп директоры Люция Закирова хыялында "челтерәсә", мәктәпнең элекке укучысы, бүген районда күп игелекле эшләре белән танылган эшмәкәр Алмаз Нотфуллинның берничә сәгать уйланулары-эзләнүләре нәтиҗәсе белән барлыкка килгән. Мәктәп ишегалдында ташлар арасыннан челтерәп агучы чишмә (рәсемдә) табигыеннән берни белән дә аерылмый: суы да чишмәнеке, тирә-юнендә камышлары да үсә. "Мин уйлаганнан да матуррак чыккан бу", – дип сокланды Алмаз, кәгазьдәге уй-ниятләрен бернинди тайпылышсыз тормышка ашырган эшчеләр хезмәтенә олы бәя биреп. Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга – такыр урында шушындый чишмә тергезүне бер җөмлә белән тагын әнә шулай бәяләп булыр иде.

Ә мәктәп коридорына, спортзалга куелган күргәзмәләр башка мәктәпләрнең дә бу юнәлештәге эшчәнлеге белән таныштыра. Укучылар һәм укытучылар фантазиясенең ни дәрәҗәдә бай икәнлеген чамалау өчен әлеге күргәзмәгә күз салу да җитә.

Конференциянең практик өлешендә чыгыш ясаган һәр бала шулай ук бик әзерлекле килүе, үз-үзен иркен тотуы белән истә калды. Сокланып, кызыксынып тыңларлык, куанып сөйләрлек эшләре бар, дигән нәтиҗәгә киләсең. Баксаң, бүгенге заман балалары безгә таныш "Зәңгәр патруль", "Яшь урманчы" диеп кенә сөйләми икән инде. Әнә Салавыч мәктәбе укучылары "Аш тозы белән суган суалчанына каршы көрәшү" ысулын тәкъдим итә, "Бәрәңгене көл белән күмеп үстерүнең уңышка һәм корткычларга тәэсире" турында сөйли. Болар һәммәсе экологик чиста продукция үстерү һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян салмас өчен кирәк, дип аңлата балалар бу шөгыльләрен. Районда биология укытучылары укытучысы дип йөртелүче Мәсхүдә ханым Әшрәпова җитәкчелегендә әле тагын башка күптөрле фәнни өйрәнү-тикшеренүләр шаһиты булганнар икән. Урталашырлык тәҗрибәләре шактый саллы булып чыкты.

Экологик белем бирүгә беренчеләрдән булып ныклап керешкән Нөнәгәр мәктәбе дә үз позициясен елдан-ел ныгыта, диделәр район мәгариф бүлеге хезмәткәрләре. Бу конференциядә әлеге мәктәп укучылары "Зур песнәкнең азык табу активлыгы"н өйрәнү нәтиҗәләрен тәкъдим итте. Песнәкләрне генә түгел, нөнәгәрлеләр, гомумән, төбәктәге кошлар дөньясын өйрәнүгә алынган булып чыкты. Кошларның төрләре, тыгызлыгы, Кызыл китапка кергән кошлар…– берсе дә балалар игътибарыннан читтә калмаган. Бу эшнең инициаторы биология укытучысы Рәйсә апалары Хәбибуллина үзе дә күп еллардан бирле кошлар белән кызыксына икән, иң мөһиме бу кызыксынуны балаларга да күчерә алган. Гомумән, мәктәпнең экологик тәрбия юнәлешендәге эшчәнлеге бик күпләргә үрнәк булырлык. Тикмәгә генә Идел буе регионында лауреат булмаганнардыр.

– Бездә һәр мәктәп аерым юнәлеш белән шөгыльләнә, – дип сөйләде район мәгариф бүлегенең экологик тәрбия бирү методисты Нурзада Сәмигуллин.– Түнтәр укучылары, мәсәлән, артышларны, Көшкәтбашлылар – каргаларны, кенәлеләр адонис чәчәген өйрәнә. Арада урманчылык белән шөгыльләнүчеләр дә, чишмәләрне кайгыртып яшәүчеләр дә, Каракүл кебек аерым күлләрне өйрәнүчеләр дә бар. Моннан ун ел элек "Экологик сукмак" дип кенә башланган бу эш, шөкер, шулкадәр тармакланды, киңәйде. Уңышларыбыз да бар: укучыларыбыз республикада төрле конкурс-олимпиадаларда ел саен 14-15 призлы урын яулый. Моннан ун ел элек Карадуганда үткән беренче конференциядән экологик катастрофа алдында торабыз, дип куркып таралышкан идек. Бер караганда, балалар көче белән нәрсә дә булса эшләп булуы да шикле кебек, әмма бүгенге күзәтү-өйрәнүләр уңай үзгәрешләр турында сөйли.

**Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА**

# Нәҗестән инеш



ХАТ

Без Базарлы Матакның Шәйдуллин урамындагы 24 нче йортта яшибез. Быел февраль аенда бакчабызның Төзүчеләр урамына чыга торган җирендә, элекке балалар йортын ремонтлап, торак йорт рәвешендә файдалануга тапшырдылар. Шуннан бирле әлеге бина гаиләбез өчен бәхетсезлек чыганагына әйләнде. Чөнки аның канализациясе, инеш булып, турыдан-туры безнең бакчага коя. Балалар бакчасы чагында аның базын торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе даими суыртып тора иде. Хәзер бинаның хуҗасы юк, күрәсең. Коммуналь хуҗалык җитәкчелеге безнең моң-зарга колак салмый. Киресенчә, минем мөрәҗәгатемә Р.Фәхразыев: "Үзәк канализациягә тоташтыруның күпмегә төшәчәген беләсеңме син?" – дип кенә кычкырды.

Мин, әлбәттә, әлеге йортны канализациягә тоташтыруның ничә сумга басачагын белмим. Әмма җир салымын даими түләп барган кеше буларак, бакчаның кемнәрдер гаебе белән пычрак су күленә әйләнмәскә тиешлеген генә аңлыйм. Бу башбаштаклыкка чик куйдыруны сорап кемнәргә генә баш имәдем. Базарлы Матак авыл җирлеге рәисе дә килеп карап китте. Файдасы тимәде. Аннан Әлки муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына кердем, карарбыз, дип өметләндереп чыгарды. Шуннан соң Чистай экологларына мөрәҗәгать иттем. Карадылар да, тагын кабатланса, административ җаваплылыкка тартып, штраф салырбыз дип хат җибәрделәр. Шуның белән вәссәлам. Хәзер инде ЖКХ министрының үзе янына барырга гына калды.

**Г.ШӘЙДУЛЛИНА.**
**Әлки районы**

# Дошман элпә

ФИКЕР

***Урамнар бүген сөенгән,***
***Ап-ак карга киенгән,***

– дип язган иде шагыйребез. Бүген ул, мөгаен, урамнар полиэтилен элпәгә төренгән, дип әйтергә мәҗбүр булыр иде. Юл буйларында, кыр-урманнарда, кая карама, шул химик элпә белән очрашабыз. Туфрак белән күмсәк тә черемичә ята бит ул, каһәр. Хәзер инде күл, инеш өсләре дә шундый чүп-чар белән капланды. Белгечләрнең әйтүенә караганда, менә шул зәхмәт балыкларның тормышын куркыныч астына куя. Хәтта дельфиннарны да һәлакәткә китерә икән. Чөнки алар су өстендә кабарып яткан полиэтилен пакетны, шар дип белеп, уйный башлыйлар һәм ялгыш йотып җибәрәләр. Авыл кешеләреннән дә, пакет өстенә пакет ашап, ашказаннары эшләми башлаган сыерларның үлеп китүе турында ишеткәнем бар.

Мондый афәттән котылу юлы бармы соң? Бар икән! Ул – таркала, эри торган пакетлар эшләп чыгару. Үзебезнең Казан технология университетында ук шундый эзләнүләр алып баручы галим эшли. Ул – техник фәннәр кандидаты Мансур Галиханов. Полимерлар һәм композицион материаллар кафедрасында хезмәт куйганга күрә, галим төргечләр ясау чималын ныклап өйрәнгән. Мансур әфәнде төргеч материалларны өч төргә бүлә. Шуларның икесе – ул акыллы һәм актив дип атаганнары – бу очракта безнең өчен әлләни кызык түгел. Ә менә эреп юкка чыга һәм хәтта ашарга яраклыларын ул биотаркалучан һәм фототаркалучан дип атый. Моңа ничек ирешергә соң? Белгәнебезчә, полимерларның полиэтилен, полистирол, поливинилхлорид, полипропилен кебекләре бөтенләе белән микроорганизмнарга каршы тора ала. "Әгәр аларның молекуляр авырлыгын 30-40 тапкыр кечерәйтә алсак, алар үзгәрергә мөмкин,– ди Мансур әфәнде. – Кайберләренә яңа катнашмалар кушсак, таркалу сәләте "ачылырга" мөмкин. Мәсәлән, полимерга крахмал өстәлсә, химик элпә бер ел эчендә череп бетә",– дип раслый ул. Чөнки микроблар, гөмбәләр белән аралашканга, крахмал бүртә, дымлана һәм үлчәме зурая. Аннан ул, глюкозага әйләнеп, полиэтиленны төреп ала. Галимнең фикере шундый.

Хәзерге вакытта иң өметлесе – сөт кислотасы белән кушылганы. Бусы бер айда таркалырга мөмкин. Шуңа да карамастан, боларны күпләп файдаланмыйлар. Чөнки җитештерүче юк.

**Дилфинә ХӘМИДИ**

# Җиде күл уртасында

БОРЧЫГАН МӘСЬӘЛӘ

**Дөньяда, мөгаен, табигатьне яратмаган, аның урман, күлләре, таулары, үзәннәре, елгаларының гүзәллеге, тереклек дөньясының матурлыгы белән хозурланмаган кеше юктыр.**



Хәер, адәм баласы үзе дә табигатьнең бик камил бер өлеше бит. Ә авыл җирендә яшәүче кешеләрне, гомумән, табигатьтән башка күз алдына да китереп булмый. Тик шунысы гына күңелгә һич тынгы бирми, хәтта авыл кешеләре дә табигать-анага зыян салырга, гүзәл җир, суны пычратырга тартынмыйлар. Күптән түгел Иске Баллыкүл авылында булып, анда яшәүче Рафик Хәйруллин белән әңгәмә корганда, моңа кабат инанырга туры килде.

Рафик яшьлек елларында Себер җирләрендә эшләп, газиз авылын сагынып кайткан кеше буларак, аның гүзәл табигатен бик үз итә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян салучыларны күралмый. "Кайбер аңламаган кешеләр белән хәтта әйткәләшеп аласың, – ди ул. – Авылыбыз янындагы бик матур күл буен Яңа Салман авылынықылар көтү куып пычрата башлагач, аларны куып җибәрергә туры килде. Тик эш узган булып чыкты. Элек күлнең тирәсе комлы иде, коеныр өчен менә дигән пляж. Терлекләр пычраткannan соң бөтен җирен камыш басты – кызынырга да, коенырга да урын калмады. Ә бит көтү чыга башлаганчы без авыл халкы белән аның тирә-ягын, төбен, өмә ясап, чистартып чыгарган гына идек".

Авыл эчендәге күлдән озын ятмәләр белән балык тотарга читтән килгән табигать корткычларын да баллыкүллеләр куып җибәрергә мәҗбүр була. Чөнки аннан үзләре балыкны күңел өчен, фәкать кармакка гына каптырып утырырга яраталар. Шөкер, авыл тирәсендәге барлык җиде күлдә дә балык бар икән үзе. Алай гынамы, хәтта кыр казлары, аккошлар шикелле киекләр дә күренгәләгән. Тик заманында 300 дән артык хуҗалыгы булган Иске Баллыкүлдә бүген 26 гына йорт утырып калганлыктан, анда яшәүче карт-коры көчләре ташып торган мылтыклы браконьерларны җиңә алмый, әлбәттә.

Рафик әфәндене иң җенләндергәне – әнә шул күл буйларына, үзәнлекләргә кайбер бәндәләрнең, үз абзарларыннан чыккан тиресне, ә иң начары – тиз генә череп таркалмый торган көнкүреш чүп-чарын чыгарып аткарулары. "Үз йортҗиремне чиста, пөхтә тотам, дип туган авылыңның әйләнә-тирәсен пычракка батыру бернинди киртәгә дә сыймый, – ди ул. – Югыйсә җиде күл уртасында утырган авылыбызның табигате бинихая гүзәл бит. Аны яшь буыннар да карап хозурланырлык халәтендә саклап каласы иде. Моның өчен, миңа калса, яшь буынны бишектән үк, җиргә пычрак ташлау түгел, төкерү дә зур гөнаһ, дип тәрбияләп үстерү зарур".

Карагыз җиде күлнең исемнәрен генә: Рушан күле, Урман күле, 2 Куак күле, Авыл күле һәм 2 Казыган күл. Ә сигез йөз еллык тарихы булган авылның исеме – Баллыкүл, имеш, кыргый бал кортларына бәйле. Көннәрдән бер көнне авыл очында үскән карт тирәк ауган. Аның эче тулы бал булган. Чөнки анда бал кортлары бал җыйган.

**Шәһит ГАТАУЛЛИН**

# Күңелем Зөя буенда

(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)

**– Димәк, Кабан күленә "Нәфис" компаниясе качып-посып кына сабын-порошок калдыклары агыза дигән сүз дөреслеккә туры килә. Әйтәм җирле, кайчак Урта Кабан турысыннан борынны капламыйча узып булмый.**

– Кайбер предприятиеләр янында без үзебезнең тикшерү постын тотабыз. Казанның уртасында калган предприятиеләрне әкренләп шәһәр читенә күчерү эше алып барыла. Соңгы 10-15 елда шул юл белән кайбер оборона предприятиеләренең шәһәр кырыена күченеп китүенә ирешелде. Хәзер яңа җитештерү корылмаларын калалардан читтә урнаштыру сәясәте алып барыла. Шул ук "Нәфис" тә үзенең рапс мае һәм сабын-порошок өчен кирәк катнашмаларны җитештерүче предприятиесен Столбищеда корды.

Транспортның һаваны пычратуын киметү өчен автомобильләрне газга күчерү бик өлгергән мәсьәлә дип уйлыйм. "Таттрансгаз", мәсәлән, үз транспортының күп өлешен газга көйләгән. Бензин бәясенең үсә баруын искә алсак, халык үзе дә моның файдалырак, чистарак икәнен аңлап алыр иде. Хөкүмәтнең энергия ресурсларын сак тотуга багышлаган утырышында биологик ягулык җитештерү турында сүз алып барылды. Шуларның берсе – соляркага аз гына кушканда да аннан чыгучы газларны киметә торган биоэтанол.

**– Сезгә кадәр эшләгән министр игътибарны республиканың санитария хәленә юнәлтеп килде.**

– Моны күз уңыннан төшерергә исәп юк. Хәзер Казан каты көнкүреш калдыкларын – эшкәртә торган ике завод корырга җыена. Аның берсе "Оргсинтез" ягына, икенчесе Биектау-Питрәч арасына утыртылыр дип исәп итәбез.

Аның белән рәттән башка мәсьәләне хәл итәсе бар әле. Ул, чит илләрдәге кебек, һәр калдыкны – пластмасса, пыяла, кәгазь һәм башкаларны – аерым-аерым җыюны көйләү. Хәзергә барлык шәһәр һәм бистәләрдә дә икенчел чимал җыю пунктлары эшләми. Каты көнкүреш калдыклары мәсьәләсе – муниципаль берәмлекләр мәсьәләсе ул. Теләкләре булгач, Әлмәт, Чаллы, Нурлат шәһәрләрендә аны, өстән әмер көтмичә, оештырып җибәрделәр. Буада калдык эшкәртү линиясе схемасын мин үзем эшләдем. Көн саен 15 чакрымга 20-23 "КамАЗ" чүп ташу тәмам чыгырдан чыгаргач, үземнең механик булуымны искә төшердем. АВМ агрегатына көйләнгән гади генә механизм, калдыкларны полиэтилен, кәгазь, металл, пыялага аерганнан соң калганын пресслап, безне баш авыртудан азат итте. Көнгә 2-3 "КамАЗ" белән котыла башладык.

**– Минемчә, моның өчен әлегә финанс таба алмый аптыраганнарга начар үрнәк түгел бу. Тик без кызык халык шул. Алда нинди генә проблема торса да, аны төптән, мәңгелек итеп чишкәнче берничә тапкыр вакытлы чара күреп карыйбыз. Әнә шул Әлмәтне генә алыгыз. Шәһәр халкына суны чистартып эчерәбез дип, берәр бүлмәле фатирлар сатып алдылар да, шунда чистарткыч җайланмалар урнаштырып чыктылар. Гәрчә, кайчан булса да бер әлмәтлеләргә җир астына су скваҗинасы төшерергә туры киләчәк.**

– Алар әлегә кадәр Чаллыдан Әлмәткәчә килә торган 80 чакрымлы сууткәргечне яңасына алыштырыргамы, әллә 20 чакрымдагы Дала Зәе дип аталган җир асты чишмәсенә коелар казып төшәргәме дигән дилемманы хәл итә алмыйлар. Быел Түбән Камада Россиядәге беренче иң зур су чистарту станциясен эшләтеп җибәрделәр. Шулай итеп ул Чаллыдагы Белоус суалгычыннан аерылды. Бу Әлмәткә барачак суның кыйммәтен элеккегә караганда да югарырак күтәрәчәк. Нефтьчеләр башкаласында аның бәһасе болай да башка калаларга караганда зуррак һәм су җитмәгәнгә күрә халык техник су кулланырга мәҗбүр иде. Мин үзем скважина төшерү кыйммәткә төшсә дә, әлмәтлеләрне чиста җир асты суы белән тәэмин итүне яклыйм. Аның авыр һәм күп акча сорый торган проект икәне аңлашыла. Ләкин сүз сәламәтлек турында барганда, башка юл юк. Мин Буага эшкә килгәндә биредәге халык суга интегә иде. Без шәһәрне артезиан коелары белән боҗралап алдык. Хәзер анда сүз суны һәр йортка кертү турында бара.

**– Буа да Буа дисез, яратып ял итә торган урыныгыз да буа буедыр әле.**

– Дөрестән дә, күңелем Зөя буенда калды.

Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА

# Чирмешән көчәя

ЭКОЛИДЕР

Чирмешән төбәге үсеп, матурайган саен, сулары ярыннан чигенә башлады, саекты Чирмешән елгасы. Соң кайбер урыннары, кем әйтмешли, җәяү атлап чыгарлык лабаса. Бетереште Чирмешән елгасы, данын-санын җуя башлады. Һәм бу аяныч хәлгә йөзләрчә чакрымлы елганың теләсә кайсы җирендә юлыгуың ихтимал.

Моңа, иң беренче булып, Чирмешән районында чаң кактылар. Бүтәннәрдә ничектер, нәкъ менә биредә борынгы елганың төбен ләмнән чистартуга, агымын тирәнәйтүгә алындылар. Берничә елда 5 километрын чүп-чардан арындырып, кем әйтмешли, диңгезгә әверелдерделәр. Тирәнлеге – ата-бабалар ысулы белән исәпләгәндә, бер-берсенә ялгаулы ике дилбегә шаедыр. Киләсе елда да бу мөһим эшне дәвам итәргә ниятләре. Ә бит ул гаять зур чыгымнар сорый. Махсус техника, елга астындагы ләмне суырган кебек үк, акчаны тиз "йотып" бара. Җөмләдән, әйләнә-тирә мохиткә тегеләйме-болаймы зарар тидергән өчен һәр оешма һәм шәхси эшмәкәр күпмедер күләмдә түләү кертергә тиеш. Аның 40 проценты җирле бюджетка китә. Ә ул исә, үз чиратында, елганы чистарту чыгымнарын каплауга тотыла. Ярап куя бит.

Ул хакта сүз кузгалгач, муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе Әмир Могыйзов: "Үзебез өчен, киләчәк өчен бит", – дип кенә куйды. Һәм шундыйрак игелекле эшләрнең байтак булачагын да сиздереп алды. Бу якларда гомердә булмаган әкәмәт гидрокорылма төзергә планлаштыралар. Монысы да су агымы белән килгән ләм янә төпкә утырмасын өчен. Ягъни су чисталыгы, экология иминлеге хакына эшләнә. Бик матур күлләре бар икән. Астан салкын чишмәләр бәреп ята. Менә шуны Чирмешән кешеләренә ял урыны итеп ясарга исәпләре.

– Ул тирәдә арка кыздырырга теләүчеләр ишле булырмы соң? – дип сорап куям.

– Ә нигә булмасын, – дип кызып дәлилләргә кереште әңгәмәдәш. – Кайбер калалар белән ярышырлыгы бар безнең район үзәгенең. 275 еллыгын бәйрәм итәргә килүчеләр сүзе бу.

Бәйрәм, юбилей дигәннән, Чирмешән авылын гөлбакча итәргә бик тырышканнар шул чорга. Урамнарны, бөтен ишегалларын өмә ясап чистарту, төзекләндерү турында гына сүз бармый монда. Елга буе булсын да, яшеллеге аз булсын, имеш. "Татнефть" ярдәм иткән үзләренә. 300 ләп төп һәйбәт чыршы – алар бүләге. Әле тагын 3 мең төп миләш, каен ише агач-куак утыртканнар. Үзәк мәйданны танырлык түгел хәзер. Үзенә күрә ял итү паркы калкып чыккан. Тәүге фонтаннар да күренә башлады.

Табигатьне, әйләнә-тирә мохитне саклау буенча Чирмешән районы алга сафта бара бүген. Башкача булмый да. Күп тапкырлар Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының мактавына ирешкән төбәк ләса. Быел алар мәртәбәле "Эколидер" исемен һәм дипломын яулаганнар.

Илдус ДИНДАРОВ

# Бәйге тәмам. Бәйге дәвам итә

"Ватаным Татарстан" газетасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы белән бергәләп газета укучылар арасында "Булмас димә" дигән бәйге игълан иткән иде. Анда без табигатьтә, хайваннар һәм кош-кортлар дөньясында булган гаҗәеп хәлләр турында язарга тәкъдим иттек. Каләм тибрәтүчеләр укучыларыбыз арасында күп икән әле. Безгә берсеннән-берсе кызыграк язмалар килде. Без аларның иң яхшыларын сайлап газетабызда бастыра бардык. Алдан вәгъдә ителгәнчә, "Ватаным Татарстан"да шушы рубрика белән чыккан барлык язмаларның авторлары республикадагы сирәк тереклек иясләрен һәм үсемлекләрне эченә алган энциклопедия – Кызыл китап белән бүләкләнә. Бүләгебезне Яңа ел алды көннәрендә кабул итеп алырсыз. Бәйге ябылмый. Ул дәвам итә. Үзегез һәм якыннарыгыз белән табигать, тереклек дөньясы вәкилләре арасында булган кызыклы хәлләр турында газетага язып торырга тәкъдим итәбез. Бер генә кызыклы язма да бүләксез калмас.

# Тыңлый торган эт һәм кош-корт

БУЛМАС ДИМӘ

**Әти-әнием дә, үзем дә, авылда терлек тотып гомер сөргән кеше булarak, хайваннарны, кош-кортларны бик яратам. Әнием гомер буе алар белән сөйләшә-сөйләшә йөри һәм һәр малы белән "уртак тел" таба иде. Күрәсең, ул гадәт миңа да әниемнән күчкән. Барча терлек иясенең сүземә колак салуыннан чыгып шундый нәтиҗә чыгарам.**

## Каз-үрдәк



Гадәттә, көз җитсә, каз-үрдәкнең су буеннан кайтасы килми. Күпләр аларны судан чыгара алмыйча интегә. Минекеләр исә елга өсте тулы "чыбык очлары" арасыннан тавышымны танып алалар. "Килегез, вакыт җитте, кайтасы-кайтасы", – дип ике-өч мәртәбә дәшүгә, каңгылдашып яр буена чыгалар. Аннан, бер җепкә тезелгәндәй тезелеп, лепер-лепер үземә ияреп китәләр. Кош-кортын су өстеннән куалап һәм ачуланып та чыгара алмаган хуҗабикәләр моңа ис-акыллары китеп карап тора. Аның сере исә бер генә: чебиләр һәм бәбкәләр белән "сары йомгак" чагыннан ук иркә генә сөйләшеп, үзеңә күнектерергә кирәк.

## Әтәч



Минем 13 тавыгым һәм бер әтәчем бар. Башта өтек кенә күренгән шул кучат тиз арада тавыкларга хуҗа булып алды. Алар янына килә башласаң, Даутны да, мине дә яратмыйча, акаеп карый, аягы белән сугып ала.

– Тукта әле, әтәчхан, нишләп син хуҗаларыңа болай кырын карыйсың? – дип аның белән аңлату эшләре алып барырга булдым. – Без бит сезнең тамакны туйдырып торучы әби белән бабай.

Ул, мине аңлагандай, күзләрен тутырып тыңлап торды да, корт-корт дип, тавыкларын чакырып ашарга кушты. Үзе борын да тидерми, күзәткәләп тора. Күрәсең, миңа: "Мин дә бит тик ятмыйм, эш кырам", – дигән сүзедер. Шушы хәлдән соң әтәчхан белән дуслашып киттек. Ул да үзенең һөнәрен күрсәтергә булды. Күрше-күлән керсә, кукраеп, өсләренә килә башлый. Мин әз генә тавышымны күтәреп дәштемме, берни булмагандай, кире борылып китә. Беркөн шулай караңгы төшеп, кунакчага менәргә вакыт җитсә дә, әтәчем әрле-бирле бакча коймасы янында йөреп тора. Карасам, анда бер тавык очып төшкән икән. Аны чыгаргач кына, "гәпләшә-гәпләшә", кетәклеккә йокларга китеп барды болар.

## Балкан



Авыл кешесенең хәбәрчесе дә, дусты да, сакчысы да – эт. Бервакыт ирем Даут юлдан кайтып керде дә, дәшеп, мине урамга чакырып чыгарды: "Чык әле, чык, менә сиңа нинди бүләк алып кайттым", – дип кулыма аклы-күкле бер көчек тоттырды.

– Абыйларның эте өч бала китергән, – диде ул. – Мин үскәндә безнең Балкан исемле бик акыллы этебез бар иде. Моңа да Балкан кушарбыз.

Үзе тиз генә умарта оясыннан оя хәстәрләп куйды. Озакламый көчегебез беренче кәсебен күрсәтеп тә өлгерде. Бер көнне Даутым тагын мине ишегалдына дәште.

– Әнә, кара тавыкларыңны, – дип мин чыгуга дүрт кызыл тавыкны сузып салган да Балканын ачуланып маташкан була. Ашау савытындагы ризыгын уртаклашырга килгән кызылкайларны буып аткан икән көчек.

– Менә, мин әйтәм, ишегалды хуҗасын хуҗалыктагы кош-корт, мал-туар белән таныштырмау бәласе. – Шулай дип, Балканны җитәкләп диярлек тавыклар янына алып килдем. – Син ярамаган эш эшләгәнсең. Болар безнең кош-кортлар, аларга тимә, – дип сөйләнәм үзем. Таякны күрсәтеп алам. Балканым күзләрен мелт-мелт йомгалап, гаебен танығандай басып тора. Шушы хәлләрдән соң ул тавык-әтәчләрне кыерсытмады. Тик капка астыннан шуышып кергән күрше тавыкларын чыгып киткәнче куалап йөри иде. Ишегалдына кеше-фәлән керсә, өреп, хуҗаларга хәбәр салды.

Көннәрдән бер көнне Әлмәттән апамның кызы Фәйрүзә килде. Аны, он чиләген алып керергә дип, баз өстенә җибәрдем. Эт лапас буендагы юл өстендә ятып тора. Үзем баскыч төбенә бастым да Балканга дәшәм:

– Бу – безнең кунак. Аңа тиясе булма, – дип бармак яныйм. Этем торып утырган җиреннән яңадан сузылып ятты. Фәйрүзә исә шул арада чиләкне күтәреп тә килде.

– Җаным чыгып китә язды куркудан. Безнең эт янынnan син шулай йөрсәң, өзгәләп атар иде. Бу этегездә кеше акыллары бар икән, күз тимәсен, – диде.

Шулай да "күз тиде" Балканга. Аның язкөз этләр туй ясаганда китеп, дүрт-биш көн югалып тора торган гадәте бар иде. Бу юлы ул ун көннән артык йортка кайтмады. Аптырап, борчылып беттек. Бер төнне өй янындагы асфальтка кайтып яткан. Ыңгыраша-шыңшый үзе. Озак та тормыйча, дөнья куйды этебез.

Тәзкирә ХАНОВА,
Минзәлә районы,
Наратлы Кичү авылы

# ... суларда кондыз

ҮЗЕМ КҮРДЕМ

**Бу вакыйга унбер еллап элек булды. Казансуның сул яры буйлап атлыйм һәм кармак салырга уңайлырак урын эзлим. Ни хикмәт, куе яшел яфраклы шактый гына юан агач ботагы, табигать кануннарына буйсынырга теләмичә, кирегә таба – Иске Чүриледән Кәчегә китеп бара. Башта исләрем китеп, тавыш-тынсыз гына бу могҗизаны күзәтеп тордым. Серле ботак минем турыдан акрын гына узып киткәч, шыпырт кына аның артыннан атлый башладым. "Балыксыз кайтсам кайтырмын, әмма бу тамашаның серен ачыкларга тырышырмын", – дидем үз-үземә. Тагын бер кызыксындырган нәрсә бар иде.**



Бераз үрдәрәк су өслегендә шактый озын агач кәүсәсе ята. Агымга каршы барган "диссидент" ботак шул агачка барып терәлгәч нишләр икән, дип кызыксына иде натуралист булып киткән абзыегыз.

Елганың тар җирендә су кызу ага. Шуңа күрә "сәяхәтче ботак" ауган агачка кадәр ашыкмый гына "үрелде". Ниһаять, "табигый кораб" кәүсәгә барып төртелде һәм агач белән яр сызыгы арасындагы кысынкы почмак эченә кереп китте. Менә берзаман ботак астыннан ашыкмый гына көрәнсу җанвар йөзеп чыкты һәм атылып каршыдагы ярга күтәрелде. Соклануымны тыя алмый телемне шартлатып куйган идем, "агач әзерләүче" шундук суга чумды. Яхшы ишетә икән. Үкендем дә инде тотнаксызлыгым өчен. Тын да алмый күзәтеп торасы урынга, ниндидер эш башларга җыенган җанварны качарга мәҗбүр иттем. Хәер, кем белә аны, бәлки ул бөтенләй курыкмагандыр да әле, "сакланганның сагы ятар" дип кенә яшеренгәндер, ә бәлки якын-тирәдә балалары булгандыр. Караңгы төшә башлаган иде инде, "кино"ның дәвамын көтеп тормыйча кайтып киттем.

Укучыларымның күбесе аңлагандыр, мөгаен, мин күзәткән җанвар халык арасында кергән кондыз була.

Моңа кадәр кондызның көпә-көндез су өстендә йөзеп йөргәнен күрү миңа насыйп булмаган иде әле. Дөрес, Ижау университетында укыткан чакта геодезия буенча җәйге күнегүләр үтүче шәкертләремнең берсе сабакташларына кондызлар турында ифрат кызыклы тарих сөйләгәнен ишеткән идем. Аның әйтүенчә, алар бик оста йөзүче җанварлар гына түгел, "югары квалификацияле" төзүчеләр дә. Кондызлар, инеш яисә елга ярының төренә карап, торакларын ике төрдә төзиләр, имеш: биек һәм текә яр буйларында ояларын җир астында әзерлиләр, ә яр сөзәк һәм тәбәнәк булса, чыбыклардан, үлән, мүк өстәп һәм ләм сылап, "хата" дип атала торган "фатир" юнәтәләр икән. Ике очракта да торак "ишеге" су астында була. Анда чакырылмаган кунаклар керә алмый.

Казансу ярларына кабат килеп күзәткәләп торсам да, таныш кондызны очратмадым. Шулай да аларның биредә төпле урнашып тормыш итүләре күренеп тора. Карандаш очлаган кебек кимереп аударылган агач кәүсәләре һәм очы югарыга тырпайган агач төпләре шул хакта сөйли. Әмма бераздан алар эшкәрткән агач кисәкләренең дә яңалары күренмәс булды. Алар гына түгел, Казансуның Арчадан түбәнге авылларында яшәгән балыкчылар да ташлады Казансу буйларын. Кала тирәсендә йөрүче электр поездында шуларның берсе белән очрашып сөйләшкәннән соң белдем: елга суы пычранган, кондызлар инешләргә күчкән, ә балык заты түбәнгә, Корткачы һәм Бөреле якларына киткән, имеш.



Су кондызы агачны карандаш кебек очлый

Аның каравы Ашабаштан Кәдрәк аша Казансуга агып үтүче исемсез инештә зур үзгәрешләр башланды. Буйдан буйга бөяләр чылбыры (русча каскад прудов дигәне) пәйда булды. Дөрес, яңа урында кондыз затына фатирларына чумып керер өчен су тирәнлеге җитенкерәмәгән. Шуңа күрә акыллы җанварлар су өслеген күтәрергә карар кылганнар. Шулай итеп, алар гидрология режимын тиз арада үз файдаларына үзгәртеп тә куйдылар. Быел җәй Кәдрәктән түбән – Казан-Арча шоссесы белән тимер юл арасындагы урыннарны берничә кабат барып карадым. Кондызлар яңа ареалда яхшы урнаштылар, бик тиз үрчеделәр шикелле. Ләкин аларны беркайчан да көндез күргәнем булмады. Яр буена төнлә барып тыңлап торсаң гына аларның плотиналарында мәш килеп кайнашканы ишетелеп тора.

Көннәрнең берсендә инеш буйлап Ашабаш ягына киттем. Шул авылдан Иске Чүрилегә туры чыга торган юлны узгач, су өстендә янә бөя күрдем. Чыдамадым, аның плотинасы аша инешнең икенче ярына чыгып карарга булдым. Бик кызыклы корылма икән кондыз төзегән плотиналар. Син атлаганда аяк астың батып киткәндәй була да, син узуга күтәрелә – янә иске рәвешенә кайта. Алар суның кондызлар яшәргә кирәк кадәрен генә тоткарлап, артыгын үзләре аша үткәрәләр.

Су кондызлары корган плотиналарның тагын бер күркәм сыйфаты бар: сыгылмалы корылма кинәт су ташкыны кузгалса да җимерелми. Фән дөньясында андый системаларны адаптив (вәзгыятьнең кинәт үзгәрүенә яраклашучы) система дип атыйлар. Тик кеше табигать хуҗалары – кондызлардан үрнәк алмый. Алар "тимер-бетон конструкцияләр" кулланалар. Шуңа күрә ташкын күтәрелсә, плотиналар җимерелеп, торак пунктларын су баса, җирле халык бик күп бәлаләргә дучар була.

Техник корылмалар гына түгел, җәмгыяви системалар да шулай корыла бездә. Ләкин "каты" системаларның иминлеге һәм тотрыклылыгы "ташка үлчим". Шуңа күрә алар вәзгыять үзгәрүенә чыдамыйлар, чәлпәрәмә киләләр. Мәгариф, авыл хуҗалыгы өлкәсендә бер-бер артлы булып торган "революцияләр" – шуның нәтиҗәсе. Минемчә, үзен "табигать патшасы" дип күкрәк кагып лаф орып кәпрәюче адәм баласына дөньядашлар тәҗрибәсен өйрәнәсе дә өйрәнәсе әле.

Шунысы да кызык бит. Алар төзелеш материалы итеп сайлаган эре агачлар, аңлавымча, болай да гомер ахырына якынлашкан була. Ауган агачның ябалдашы җир өстенә барып төшсә, бу оста гидротехниклар аны кимереп кыскарталар да куе яфраклы өлешен түбәнгә өстерәп төшерәләр.

Кышка таба торакларына якын урыннарда кайрысын ашарлык агач кисәкләрен җыеп куялар. Үземне иң сокландырганы – кондызның суда искиткеч оста йөзүе. Ятмәле арткы тәпиләре ифрат камил ишкәк ролен уйнаса, бик көчле яссы койрыклары йөзгәндә руль, эшләгәндә утыргыч булып хезмәт итә. Куркыныч янаганда кондыз койрыгын сигнализатор итеп тә файдалана. Су өслегенә шапылдатып сугып, туган-тумачасын кисәтә. Гәүдәсе бер метрга, койрыгы 30 сантиметрга җиткән, ә авырлыгы утыз килодан да артып киткән бу җан иясе, бергә-бер очрашканда, бүрегә дә бирешми. Тик адәм баласыннан саклана.

Хәер, аларның кешеләргә үрнәк булырлык тагын бер сыйфаты бар икән әле. Кондызлар гаилә корганнан соң бер-беренә гомер буе тугрылык саклый, балаларын тәрбияләүдә икесе дә актив катнаша. Америка һәм Азия кыйтгаларында яшәүче халыкларның шактые бу серле җанварларны юкка гына изге затлар дип ихтирам итмиләр, күрәсең.

Ким ШАКИРОВ

# "Татнефть" һәм чишмәләр

Республиканың көньяк-көнчыгышындагы кадәр чишмәләр, Татарстанның гына түгел, Россиянең башка төбәкләрендә дә юктыр. Бу – "Татнефть" компаниясенең соңгы елларда су чыганакларын чистарту, яңарту, яңа кизләүләр ачу сәясәте нәтиҗәсе.

Һәр ел акционерлык җәмгыятенең бүлекчәләре арасында иң яхшы чишмәгә һәм суның сыйфатын яхшыртуга бәйге игълан ителә. Көзен аңа нәтиҗә ясала. Шушы рәвешле ун ел эчендә "Татнефть" бүлекчәләре 550 дән артык су чыганагын савыктырдылар. Аларның күбесе авыл һәм бистәләрнең бизәгенә әверелде.

Бүгенге көндә авыз тутырып әйтергә мөмкин: "Татнефть" эшли торган мәйданнарда чистартылмаган чишмә калмады дип әйтерлек. Иң шатландырганы шул, нефтьчеләрдән үрнәк алып, әлеге кала һәм салаларда яшәүче кешеләр дә чишмәләрне төзәтеп, чистартып тора башлады.

Болар берсе дә буш сүз түгел. Компаниянең экологлары һәр кизләү янына куелган игъланнар тактасында суның составын күрсәтеп, язып баралар. Ә ул саннар суларыбызның сафлана баруы турында сөйли. Моңа компаниянең үзендә табигатьне сакларлык технологияләр куллану аркасында да ирешелә.

Хәзерге көндә "Татнефть" 2005-2008 елларга исәпләнгән экология сәламәтләндерү программасы кысаларында эш алып бара. Ул, су чыганакларын чистартуны гына түгел, аларны пычратудан саклап калу чараларын да үз эченә ала.



Экологик бәйгедә һәр елны диярлек җиңүчеләр рәтендә барган "Җәлилнефть" савыктырган чишмә.

Кушымтаның мөхәррире – Илсөяр ХӘЙРУЛЛИНА. Биткә салды Зөлфия МАДЬЯРОВА. Д.БУНТУКОВ фотолары

ecology01.p65 2 23.03.2010, 10:37